**БЕЗ ҺӘРВАКЫТ БЕРГӘ!..**

**БҮГЕНГЕ НОМЕРДА:** **“Кәрәзле телефонның файдасы һәм зыяны” (2нче бит)**

**“Спорт илендә” (3нче бит)**



# ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ

Тираж 30 экземпляр

№4 30нчы гыйнвар Пәнҗешәмбе

**Балалар һәм яшүсмерләр гәҗите** ★ **http://vkontakte.ru/club30613368**

## ЯҢАЛЫКЛАР

14нче февраль көнне Гашыйклар көненә багышланган “Йөрәктәге хисләр” акциясе үткәрелә

“Мисс һәм Мистер Январь” конкурсының нәтиҗәләре билгеле. Грамоталар җиңүчеләргә 30нчы гыйнвар көнне линейкада тапшырылачак.

2012нче ел Россия тарихы елы булып билгеләнде.

Безнең мәктәптә өлкән кешеләрне компьютерга өйрәтү курслары башланды.

25нче гыйнвар көнне безнең мәктәптә “Кәрәзле телефонның файдасы һәм зыяны” конференциясе узды.

Марина апа һәм Гүзәл апа җитәкчелеге астында 3, 7, 8 нче сыйныф укучылары “Играют все!” конкурсында катнашып 1нче урын алдылар.

17нче гыйнвардан 21нче гыйнварга кадәр рус теле һәм әдәбияты атнасы үтте.

14нче гыйнвар көнне чаңгы шуу сезоны башланды.

ЕГЭда үзгәрешләр көтелми.

## БУ БИК КЫЗЫК

Дөньяда иң зур мел белән ясалган рәсемнең озынлыгы 8361, 31 метр. Бу рәсемне Калифорниядәге Алмеды мәктәбендәге 5578 укучы ясаган.

Ләкләкләр йоклаган килеш 10 минут дәвамында оча алалар.

Песиләр көненә 16 сәгать йоклый алалар.

Уртача болыт авырлыгы 1 тоннага җитә.

Украинадагы иң олы үгез авырлыгы - 1,5 тонна.

Ана песиләр балаларын муеныннан тотып йөри. Ни өчен? Шунда “нерв төене” урнашкан. Ана песи баласының муеныннан тотса, песи баласы кыймылдый алмый.

*Интернет ресурсларыннан алынган.*

## КОТЛЫЙБЫЗ

10нчы февраль көнне безнең физкультура укытучысы Нияз абыйның туган көне.

***Нияз абый!***

*Котлыйбыз Сезне туган көнегез белән! Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, эшләрегездә уңышлар, балаларыгызның сәламәт һәм бәхетле булуын телибез!*

*Сезнең укучыларыгыз.*

★★★★★★★★★★

17нче гыйнвар көнне безнең Шәмсетдинов Ильясның туган көне.

23нче гыйнвар көнне безнең Гумиров Илсурның туган көне.

7нче февраль көнне безнең Саниев Айнурның туган көне.

7нче февраль көнне безнең Марданшин Илнурның туган көне.

31нче гыйнвар көнне безнең Исламова Илүзәнең туган көне.

***Дусларыбыз!***

*Котлыйбыз сезне туган көнегез белән! Сезнең сәламәт булуыгызны, һәрвакыт “5” билгесенә укуыгызны телибез!*

*Мәктәп дусларыгыз.*

# ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Без 11нче сыйныф укучылары мәктәптә яңа ел бәйрәмен үткәрдек. Иң беренчедән, укытучыларыбыз, алып баручыларыбыз барыбызны яңа ел белән котлап, яхшы теләкләр әйттеләр. Без кунакларга чит илләрдә яңа елны кем ничек үткәрүен күрсәттек. 9нчы сыйныф кызлары Япония һәм Һиндстан илләреннән бүләкләр алып килделәр. 7нче сыйныф кызлары ирланд биюен, ә егетләре “Татар кызлары” биюен биеделәр. Хакимова Энҗе һәм Саниев Айдар Грузия яңа елын күрсәттеләр. Саниев Айнур бик яхшы итеп Италия яңа елы традицияләрен сөйләде. Габдуллина Гөлназ үзенең матур җырлары белән сөендерде. Кызыклары уеннар уйнадык. Барлык укучылар да актив катнашты. Кыш Бабай һәм Кар кызы бүләкләр оләшеп киттеләр. Лотереяга бик матур бүләкләр чыкты, суперпризны Хәйбрахманова Гөлназ отты. Бәйрәмне күңелле дискотека тәмамлады.

*Айдар Саниев, Алсу Идиятова, 11нче сыйныф укучылары*

## Кәрәзле телефонның файдасы һәм зыяны

25нче гыйнвар көнне 11нче сыйныф укучылары физика программасы кысасында “Кәрәзле телефонның файдасы һәм зыяны” дигән проект эшләрен күрсәттеләр. Укучылар өч юнәлештә: “Кәрәзле телефоннар турында галимнәр” (Саниев Айдар); “Кәрәзле телефоннарга медиклар карашы” (Идиятова, Габдуллина); “Кәрәзле телефоннарның зыянлылык критерийлары” (Хәертдинова, Хайруллина) эшләделәр. Һәрберсе үз чыгышында кәрәзле телефоннарны куллану кагыйдәләрен тамашачыга җиткерделәр. Бу барыбыз өчен дә бик яхшы киңәшләр:

1) телефоннан бер минуттан артык сөйләшмәскә тәкъдим итеלә;
2) машина йөрткәндә телефоннан сөйләшергә ярамый;
3) йокларга ятканда телефонны сүндереп читкә куярга, ләкин мендәр астына куярга ярамый;
4) өйдә чыбыклы телефоннан күбрәк сөйләшергә;
5) телефонны күп вакыт сүндереп торырга.

Иң әз нурланыш бирә торган телефоннар: Motorola, Panasonic.

*Алсу Идиятова, 11нче сыйныф укучысы*








# СПОРТ ИЛЕНДӘ

Көннән көн безнең яшьләр хоккейны тагын да ныграк ярата башладылар. Әйтелгәнчә, яшьләр ике командага бүленде. Һәрбер командада запас уенчылар бар. Стәрле яшьләре Җиңү бистәсе мәктәбе укучылары белән уеннарны башлады. Башта алар безгә, аннан соң без аларга барып уйнадык. Вакыт бик күңелле узды. Икенче авыллар белән уйнаганда Стәрле хоккей командалары берләшеп уйныйлар. Түбәндә чит авыллар белән уйнаучы команда составы китерелгән:

| № | Ф.И.О | Амплуа | Команда |
|---|---|---|---|
| *7* | *Сагутдинов И.А* | *вр* | *Хк «рысь»* |
| *11* | *Латифуллин Р.Р* | *вр* | *ХК «Стярле»* |
| *5* | *Сагутдинов Р.Р* | *защ* | *Хк «рысь»* |
| *31* | *Идиятов И.Н* | *защ* | *ХК «Стярле»* |
| *26* | *Миннегалеев Б.И* | *защ* | *ХК «Стярле»* |
| *12* | *Саниев А.Р* | *защ* | *Хк «рысь»* |
| *95* | *Марданшин И.К* | *нап* | *Хк «рысь»* |
| *99* | *Саниев А.Р* | *нап* | *ХК «Стярле»* |
| *19* | *Шамсутдинов Н.А (К)* | *нап* | *Хк «рысь»* |

Бу уеннарның нәтиҗәләре.

**ХК “Стәрле” 30 : 3 ХК “Ice Various”**

**ХК “Стәрле” 15 : 7 ХК “Ice Various”**

**Хөрмәтле авылдашлар!**

Стәрле яшьләре Нияз абый җитәкчелеге астында хоккей корты ясый башладылар. Бу мәсъәләдә безгә Солтанов Илшат абый, Сагадатов Вәрис абый, Сөнагатов Илмир абый, Тухбатуллин Дамир абыйлар ярдәм кулы суздылар. Бөтен укучыларыбыз исеменнән бик зур рәхмәт белдерәбез.

Хоккей кортынын яртысы ясалды. Ләкин эше бетмәде әле. Авылдашларыбыз! Сездән тагын ярдәм сорыйбыз. Хоккей кортының эше күп калмады.







*Рамазан Латифуллин, “Спорт бүлеге” корреспонденты*



# Мисс һәм Мистер Январь

Безнең мәктәптә иң яхшы укучыны билгеләр өчен “Мистер һәм Мисс Декабрь” конкурсы оештырылган иде. Алдан ук әйтелгәнчә, бу конкурс ай саен үтәчәк. Гыйнвар аенда конкурс өчен шулай ук Айзәрә Солтанова җаваплы булды. Ул бу эшкә бик җитди килде. Укучыларны алдан билгеләнгән өч критерий буенча тикшерде. Әйткәнебезчә, бу конкурс җиңүчеләре, ай азагында грамота белән бүләкләнәчәкләр. Зур класслар арасында җиңүчеләр:

1. Солтанова Айзәрә- 10нчы класс укучысы
2. Миннегалеев Булат- 8нче класс укучысы

Кечкенә класслар арасында:

1. Хәертдинова Миләүшә- 3нче класс укучысы
2. Абдуллин Илнар- 5нче класс укучысы

Котлыйбыз! Ә “Мисс һәм Мистер Февраль” конкурсы эшен 1нче февраль көненнән башлый. Укучыларыбызга уңышлар телибез!

*Айзәрә Солтанова, конкурслар бүлеге корреспонденты*

# Йөрәктәге хисләр

Озакламый, Гашыйклар көне килеп җитәр. 14нче февраль көнне “Яшьләр каласы” газетасы бер-беребезгә котлаулар язышу акциясен башлый. Котлаулар да төрле формада була: сүзләр белән, открыткалар бүләк итү. Почта шулай ук редакция кабинетында сакланачак. Кадерле дуслар, 14нче февраль көнне сез котлау хатлары язачаксыз, шул ук көнне почтальоннар сезнең хатларыгызны адрес буенча тапшырыр. Шулай ук, эйтеп китәбез, адресатларга VIP – открыткалар җибәрергә мөмкинлек булачак. Алар түбәндәге үрнәктә булачак:

1. Открытка + чәчәк
2. Открытка + шигырь
3. Открытка + кәнфит

Бу VIP – открыткаларны җибәрер өчен сез почта эшләгән көннәрне редакциябезнең баш редактор ярдәмчесе Энҗе Хакимовага эндәшергә тиеш буласыз. Барлык сорауларыгызны шулай ук Энҗе Хакимовага, яки группада (**http://vkontakte.ru/club30613368**) бирергә була.

*Энҗе Хакимова, баш редактор ярдәмчесе.*

# БЕЗНЕҢ МӘКТӘП ТУРЫНДА …

Стәрле яшьләре мәктәләрен бик ярата, укытучыларын, бер-берсен хөрмәт итә. Шуңа күрә без барыбыз да дус булып яшибез. Вакыт та бик күңелле үтә бездә. Көн саен яңа эшләр башкарыла. Конференцияләр, фән атналары, бәйрәмнәр үтә. Мәктәп тормышында бик актив катнашабыз! Нинди яңалык кертергә дип уйладык? Бик озак уйларга туры килмәде. Карагыз әле, дуслар, безнең мәктәптә депутат та бар, аның эше бик яхшы күренә. Барыбызга да кирәк чагында ярдәм итә. Димәк, мәктәбебез кечкенә үзенчәлекле бер дөнья, яки ил, булып тоела. Һәрбер илнең президенты бар, безнеке дә бар! Һәрбер илнең үз гимны бар. Ә бездә юк иде. Күптән түгел, Гөлназ апабыз белән бергә мәктәп гимнын уйлап яздык. Бик әйбәт килеп чыкты. Хәзер инде гимнны һәрбер укучыга таратып, ятларга бирәбез. Укучыларыбыз арасыннан, гимн җырлаучы кешеләрне сайлыйбыз. 23нче февраль көнне построениеда гимнны беренче тапкыр башкарырбыз. Тагын нәрсә уйладык без? Һәрбер илдә флаг бар. Ә бездә юк әле ул. Шуңа күрә, “Яшьләр каласы” газетасы тагын бер конкурс оештыра. Балалар мәктәп флагын уйлап чыгарып, А4 форматтагы биткә рәсемен ясап, шул битнең арткы ягына аңлатмасын язып тапшыралар. Укучыларыбыз 14нче февральга хәтле эшләрен бирергә тиеш. Барлык рәсемнәрдән иң тирән мәгънәле флагны сайларбыз һәм шул флаг – мәктәп флагы булып танылыр. Жюри составына редакция эшчеләре керә. Ярдәмгә Асия апабызны һәм Зәбирә апабызны чакырабыз. Нәтиҗәләре “Яшьләр каласы” газетасында басылып чыгар.







# БЕЛДЕРҮЛӘР

14нче февраль көнне “Йөрәктәге хисләр” акциясе эшен башлый. Хатлар языгыз!

17нче февраль көнне мәктәптә Гашыйклар көненә багышланган ял кичәсе оештырыла. Башлана: 18 – 00 сәгаттә.

*Данил Миннебаев, “Белдерүләр бүлеге” корреспонденты*

# БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

Гәҗитебезнең дүртенче номеры 30нчы гыйнвар көнне чыкты, чөнки ай башы каникулларга туры килде. Башка вакытта, әйткәнебезчә, айның 15 һәм 30нчы көннәрендә чыгар. Үзгәрешләр булса, баш редактор сүзе бүлегендә әйтелеп китәр.

**Кадерле дуслар!**

Барыгызны да 3нче чирек башлануы белән котлыйм! Барыгызга да ныклы сәламәтлек, эшләрегездә, укуыгызда яңа уңышлар телибез! 3 нче чиректә барыгыз да укуны “5”леләргә тәмамларсыз дип көтәм!

Басылды: МБОУ “СОШ с.В. Стярле” 30 экземпляр Телефон: 8 (85592) 42743



ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ

**Баш редактор**
**Ильнур Марданшин**

**Редакция адресы:** 423314, ТР, Азнакай районы, Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 38 Б, инглиз теле кабинеты, “Яшьләр каласы” гәҗите редакциясе. http://vkontakte.ru/club30613368

Гәҗит аена ике тапкыр чыга, сату хакы – килешү буенча.

**Баш редактор ярдәмчесе:** Э.Хакимова
**Беренче бит бүлеге:** Р. Гатиятов
**Спорт бүлеге:** Р. Латифуллин
**Конкурслар бүлеге:** А. Солтанова
**Бәйрәмнәр бүлеге:** Р. Сахапова
**Белдерүләр бүлеге:** Д. Миннебаев
**Фотограф:** Г. Хайбрахманова
**Художник:** И. Марданшин
**Комп.вёрстка:** Г.И.Хайруллина